Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

“16” октябрь 2019 ел № 131

**Арча шәһәр Советының “Физик затларның мөлкәтенә салым турында” 2015 елның 3 ноябрендәге 7 нче номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясының беренче өлеше һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә Арча шәһәре Советы КАРАР бирде:

1. Арча шәһәре Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 7 нче номерлы «Физик затларның мөлкәтенә салым турында» Карарына (Арча шәһәре Советының 2018 елның 29 ноябрендәге 108 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 2 пунктында:

1.1.1. 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) 0,2 процент:

фатирга, фатирның өлешенә;

бүлмәгә карата;»;

1.1.2. 3нче пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«торак йортлар, торак йортларның өлешләре;».

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салымны исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан, игълан ителгән көннән бер ай узганнан соң гына үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Арча хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев